
# ЧИШМӘ БАШЫ

**МБМБУ "Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"**









| №1 | НОЯБРЬ | 29.11.2024 |
|---|---|---|

Ана –Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга?!
Хатыннарның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке – ана булуда. **Һади ТАКТАШ**

## ӘНИЛӘР КӨНЕ





**Әниләр көне белән!**
Әниләрне котлыйм бүген
Әниләр көне белән!
Әни булу бәхете ул –
Иң олы бәхет, беләм!
Бәхетле була әниләр,
Баласы тәртипле булса,
Үз юлын тапса тормышта,
Яраткан эше булса.
Бәхетле була әниләр,
Балалар хәлен белсә.
Яннарына вакыт табып,
Җай табып, кайтып килсә.
Бала кайгысын күрмәсә,
Бәхетле була ана!
Чын күңелдән бәхет телим
Бүген һәрбер анага!
**Раил ГАТАУЛЛИН**

Россия Федерациясе Президентының 1998 елның 30 гыйнварында чыккан 120 номерлы карары нигезендә, илебездә ноябрь аеның соңгы якшәмбесе ел саен “Әниләр көне” булып билгеләп үтелә. Быел ул 24 ноябрь көненә туры килә.

Илебездә билгеләп үтелә торган күпсанлы бәйрәмнәр арасында әниләр көне аерым урын алып тора. Бәйрәмнең максаты – хатын-кызга сакчыл караш традицияләрен хуплау, гаилә нигезләрен ныгыту, безнең тормышта төп кешенең – әнинең әһәмиятен аеруча билгеләп үтү. Бу бәйрәм беркемне дә битараф калдыра алмый. Нәкъ әниләр көнендә үз балаларына мәхәббәт, игелек, наз бүләк итүче барлык аналарга рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Тик нинди генә җылы сүзләр әйтсәк тә, җитмәс төсле... Әниләр көне – искиткеч көн. Безнең һәрберебез әниебезне искә төшерергә, аңа шалтыратырга, бәлки янына кайтып, аны котларга, аның сәламәтлеге һәм кәефе ничек булуы белән кызыксынырга тиешле көн!

Мөлаем һәм ягымлы күзле, акыллы, сабыр һәм түземле, шәфкатьле, авыр вакытларда арканы сыйпаучы кадерле куллы, боз эретерлек җылы сүзле, бала өчен кайгырып, төннәрен күз йоммаучы әниләребез, сезне бәйрәмегез белән чын йөрәктән котлыйбыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер, рухи көч, тормыш зирәклеге, сабырлык, бәхет, гаилә иминлеге телибез. Безгә биргән чиксез мәхәббәтегез, назыгыз һәм кайгыртуыгыз өчен рәхмәт!



### Әниләр хакында кызыклы фактлар

Россиядә Әниләр көне ел да ноябрьнең соңгы якшәмбесендә билгеләп үтелә. Дөньяның 20 илендә аны май аеның икенче якшәмбесендә уздыралар. Әлеге илләр арасында АКШ, Канада, Германия, Италия. Бельгия, Дания, Финляндия, Төркия, Япония, Австралия дә бар. Грециядә – 9 майда, Грузиядә – 3 мартта, Белоруссиядә 14 октябрьдә бәйрәм итәләр.

СССР вакытында әниләр өчен махсус бүләкләүләр булган. Әйтик, биш-алты бала табып үстергән әниләргә – «Ана медале», 7 – 9 бала тапканнарга – «Ана даны» ордены, ә ун һәм аннан күбрәк бала тапканнарга «Герой-ана» исеме һәм ордены бирелгән. Яу кырына лачындай уллар үстереп биргән солдат аналары хөрмәтенә куелган һәйкәлләр Россиядә дистәдән артык.

Россиядә Әниләр бәйрәменең символы – күгәрчен күзе чәчәге (незабудка).

Казанның Җиңү паркында да яу кырында ятып калган Солдат анасына һәйкәл бар. Дүрт метрлы ана сыны кулына кайгы һәм хәтер билгесе булган лалә чәчәкләре тоткан.





# ГАИЛӘ – УЛ БӘХЕТ!

Гаилә сүзен әйткәч, үзебезнең иң якын, иң кадерле кешеләребезне, үзебез яшәгән өебезне, безне чолгап алган көндәлек таныш табигатьне күз алдына китерәм.

Гаилә ул бик олы сүз. Әти-әни, әби-бабай – гаиләнең иң хөрмәтле кешеләре. Абый- апаларыбыз безне кайгырталар, эне-сеңелләребез безнең ярдәмгә мохтаҗ. Кешеләр бер-берсен кайгыртып яшәргә, бер-берсенә таяныч булырга тиеш.

Димәк, гаилә - ул олы таянычыбыз, иң ышанычлы сыенып урыныбыз. Анда бер-берсен яраткан, бер-берсе турында кайгыртучанлык күрсәткән кешеләр яши.

Һәр гаиләнең үз кагыйдәсе, традициясе, кыйммәтләре була. Традиция – тарихи барлыкка килгән һәм буыннан буынга күчә торган гореф-гадәтләр, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, карашлар, зәвыклар.

Минемчә, гаилә нык, тату икән, димәк дәүләт тә нык, тату дигән сүз. Һәр кеше бәхетле гаилә корырга омтыла.

> Гаилә – кеше өчен иң мөһим, иң җаваплы эш. Гаилә кешегә бәхет китерә, ләкин һәр гаилә, беренче чиратта дәүләт күләмендә мәгънәгә ия булган зур эш булып тора.
> А.С.Макаренко

Бәйрәмнәр, гореф-гадәтләрне безгә әби-бабаларыбыз өйрәтә. Кош, оясында нәрсә күрсә, очканда шуны эшли, ди халык. Гаиләләр милли традицияләргә уңай караштa, татар милләтенең үзенчәлекләрен исәпкә алып, саклап яшәргә тырыша. Милли традицияләр белән яшәү балага нинди исем кушудан башланып, аның туган телендә теле ачылуны, йортта урнаштырылган тәртипне, нинди азыклар белән туклануны, туганнар арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм башкаларны колачлый.

## Психолог киңәшләре

Бала тәрбияләүдә мактау һәм шелтә бик зур роль уйный.

- Тәрбиядә әти белән әни бер сүздә булып, таләпләр тотрыклы булырга тиеш. Ата-ана кәефе яхшы булганда баласына нәрсә теләсә, шуны эшләргә рөхсәт итә, кәефсез булганда бар нәрсәдән дә тыя икән, бала алга таба бөтенләй тыңламый башларга мөмкин.
- Бала тәрбияләүдә мактау һәм шелтә бик зур роль уйный. Баланы җәза бирү юлы белән тыңлатырга күнеккән булсагыз, бик нык ялгышасыз. Тәрлечә мактау, хуплау юлы белән яхшырак нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.
- Ата-ана мәхәббәте баланы киң күңелле, ягымлы, ачык йөзле итә. Шушы мәхәббәт җылысы балада намуслылык, йомшак күңеллелек тәрбияли. Ләкин баланы нык яратам дип, чама хисен югалтмагыз. Югыйсә үз ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән баш тарта алмый торган кеше үсәргә мөмкин.
- Әти-әни – улы һәм кызы өчен камиллек үрнәге. Бала аңына ата һәм аның ролендәге кеше шундый булырга тиеш дип сеңдереп үсә. Балагыз өчен яхшы үрнәк булырга тырышыгыз.
- Балада эгоизм, ялкаулык, ялганлау кебек начар сыйфатлар күренсә, бу – хәвефле сигнал. Әлеге сыйфатлардан шәфкатьсезлеккә дә ерак түгел. Шәфкатьсезлек кансызлык китереп чыгара. Шуңа күрә балагызның ни белән кызыксынуын, даими шөгыль һәм ял итү урыннарын, кемнәр белән аралашканын белеп торыгыз, укытучылары, иптәшләре белән мөнәсәбәтләреннән хәбәрдар булыгыз.
- Гаиләдә бергәләп китаплар укыгыз, җырлар һәм музыка тыңлагыз, табигатьтә ял итегез. Шушы татулык һәм бердәмлек аша эстетик кыйммәтләр пәйда була, әхлак тәрбияләнә.

# КАЗ ӨМӘСЕ

**Каз өмәсе** - көзен, кыш кергәндә казларны өмәләп эшкәртү чарасы. Каз өмәсе – ул матур итеп аралашу, күңел ачу, үзеңне күрсәтү дә булып торган. Каз мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясыйлар. Каз итеннән аш-су өчен бик әйбәтләп файдаланалар. Татар яшьләре каз өмәсен аеруча көтеп ала торган булганнар. Каз өмәсен бигрәк тә кызлар көтеп алган. Аннан читтә калмас өчен, алар бәбкәләре күп булган апаларга җәйдән үк сүз салып куйганнар. Бу гаиләгә охшарга, ярарга тырышканнар. Йолкыган казларны көянтәгә асып кызлар чишмәгә, су буена алып төшкәннәр. Шул суда казларны юганнар. Гадәттә, гармуннар тагып, кызлар белән бергә егетләр дә чишмәгә төшкәннәр. Казларны юып кайтышка, хуҗабикә каз маенда коймак, тәбикмәк пешереп, чәй әзерләп көтеп торган. Кичке мәҗлес тәмамлангач, йортта яшьләр уены оештырылган.

Каз өмәсе һәр елны көз ахырында яисә кыш башында үткәрелә. Ул — бүтән өмәләрдән аермалы буларак, башыннан азагына кадәр кызлар өмәсе.

Башка өмәләр кебек, каз өмәсен оештыру һәм уздыруның да үзенә генә хас тәртибе бар. Казлары күп кешеләр иртәгә өмә уздырыласы көнне кызларны чакырып чыгалар. Беренче чиратта туган-тумачаны, күрше кызларын дәшәләр. Гадәттә, өмәгә чакыру эше балаларга кушыла.

Әйтелгән көнгә кызлар иртүк килә. Казларны эшкәртәләр, зур канатларын йолкып сыдыралар. Иң оста чистартылган казның бер генә шырпысы да (канат төпләре) калмый һәм бер җирдә дә тиресе ертылмый.

Казлар йолкынып, эчләре алынып, аяк-башлары чистарты-лып бетә. Өмәнең иң күңелле вакыты — чистартылган казларны, көянтә башларына элеп, кызларның су буена юарга баруы. Алар белән, сыдырылган канатларны алып, яшүсмер кызлар да бара. Алар канатларны су юлына бара торган сукмак буйлап тараталар. Монысы киләсе елда хуҗабикәнең казлары сукмакны тутырып йөрсен дигән теләк белән эшләнә. Кызларның кайберләре өй җыештырырга кала.

Су буеннан кайтуга, кызларны «каз коймагы» көтеп тора. Каз коймагына күршедәге ятим карчыклар да чакырылырга мөмкин. Ашаганнан соң, кызларның бер өлеше, каз боткасы пешерү өчен, кәйледә ярма күзләргә (төеп чистартырга) китә. Караңгы төшәр алдыннан өмәдә катнашкан кызларның әниләре ашка чакырыла. Аларга каз шулпасында токмачлы аш, каз калҗасы белән бәрәңге, каз ите белән бәлеш пешерелә.

Каз өмәсенең иң кызыгы кич белән. Кызлар, матур күлмәкләрен киеп, өмә булган өйгә җыелалар. Җор телле, тапкыр сүзле кызлар ишек төбенә баса. Алар каз канаты «сата». Егетләр өйгә һөнәрләрен күрсәтеп, канат «сатып» алганнан соң гына кертелә.

Кунак җыю, кунак сыйлау татар халкында гомер-гомергә дәрәҗәле эш исәпләнгән. Туганнарың, күршеләрең, авылдашларың белән аралашып, ашка-суга йөрешеп яшәү тормышны тагын да ямьләндереп җибәргән. Өмәдә эшләнгән эшләр, уен-көлке хатын-кызга ел буена җитәрлек дәрт биргән. Ул көнне хатын-кызларның ни дәрәҗәдә уңган булулары ачыкланган.

## Балалар сөйләшә

Әбисе Ниязны баздан бәрәңге алып чыгарга чакырган, ә аның малайлар белән уйнап йөргән чагы була, бер дә бүленәсе килмичә: “Дәү әни, әллә инде үзең баз авызына сыймый башладыңмы?” - дип җавап биргән

## ӘНИЛӘР КӨНЕНӘ БҮЛӘК ИДЕЯЛӘРЕ

**Күбегездә ел саен «әнигә нәрсә бүләк итим?» дигән сорау туадыр, мөгаен. Без сезгә бу эштә ярдәм итәргә булдык.**

Әниегезнең кызыксынуларыннан, теләкләреннән, хыялларыннан чыгып, аңа якын булганын, үзегез ошатканын, акча җитәрлек бүләкне сайлагыз. Мисал өчен, әниегез бакчачылык белән кызыксынса, аңа чигү өчен набор бүләк итү бик үк урынлы булмас. Шуңа күрә я әтиегез аша, яки үзегез сиздермичә генә сораулар биреп, моны билгеләгез.

**Номерлар буенча рәсем буяу**

Моны балачакка кайту дип әйтсәң дә була. Бөтенебез дә буягычларны ярата идек бит. Номерлар буенча рәсем ясауның өстенлекләре шактый күп. Беренчедән, җыелмада иҗат өчен кирәке бар әйберләр дә инде булачак. Икенчедән, мондый төр буягычларда күңелгә ошаган теләсә нинди рәсемне сайлап була. Өченчедән, бу шәп антистресс. Рәсем ясаганда ярткан җырларны тыңлап, күптән карарга теләгән сериалны карап була. Ә дүртенчедән, мондый рәсемнәр бүлмәне бизәргә дә шәп.

**Иҗади остаханә**

Әниегезгә балчык, пыяла, пластилин һәм башка материаллар белән эшли торган иҗади остаханәләргә сертификат бүләк итә аласыз. Беренчедән, бу бүләк анда булган иҗади потенциалны үстерергә ярдәм итәчәк. Икенчедән, үз кулы белән ясаган эшләнмә бу көнне һәм бүләкне җылы хатирә итеп истә калдырырга ярдәм итәчәк. Шулай ук сертификатны ашарга пешерү һәм башка остаханәләргә дә бүләк итеп була.

**Әниегезнең коллекциясен тулыландырыгыз**

Күп кеше берәр нәрсә җыю белән кызыксына. Кайберәүләр фарфор уенчыклар җыя, икенчеләре – тәлинкәләр, өченчеләре – чыршы уенчыклары. Кыскасы коллекцияләр төрле була ала. Әниегез, мөгаен, мондый бүләккә бик сөенер.

**Гөл үстерү өчен җыелма**

Гадәттә, әниләр чәчәкләр бик яраталар. Шуңа үз куллары белән үстергән гөл аңа аеруча хуш килер. Бу җыелманы сез үзегез дә эшли аласыз. Гөл орлыгы (яисә тамыры), җир, чүлмәк, махсус кораллар. Шуны матур итеп төреп, бантлар куеп, бүләк итү уңышлы булыр.

**Җыештыру өчен кирәк җиһазлар:**

**Швабра**

«Үсеп җиткән кызым бар, ә мин иелә-бөгелә идән юам!». Мондый сүзләрне ишеткәнегез булса, бу– әниегезгә шәп швабра алып бирергә вакыт дигән сүз. Бүгенге көндә аларның ниндиләре генә юк, пар белән юа торганнары да, үзләре сыгыла торганнары да, бик җиңел һәм кечкенәләре дә.

**Тузан суыткыч робот**

Өйдә гел чиста булуын теләсәгез, тузан суырткыч робот алыгыз. Моны әтиегез, абый-апаларыгыз белән кушылып бүләк итсәгез шәбрәк булыр.

**ВАКЫТНЫ БЕРГӘ ҮТКӘРЕГЕЗ**

Әниләр көнендә нинди генә бүләк бирсәгез дә, аналар өчен балалары белән вакыт үткәрү, аларның игътибарына күмелү иң зур бүләк булачак. Шуңа да бергә эшли ала торган бүләкләрне дә бу исемлеккә кертергә булдык.

**Фотосессия**

Фотопараты булган дустыгыз яисә профессиональ фотографка мөрәҗәгать итеп, бу көнне сурәтләп калдыра аласыз. Икегез дә бертөрлерәк киенеп, матур локацияләрдә фотога төшү, ә аннан соң бергәләп каһвә эчү әниегезгә хуш килер, дип уйлыйбыз.

**Кичке аш**

Әниләр болай һәр көн диярлек ашарга пешерә. Бу көнне әлеге эшне үз өстегезгә алыгыз. Әниегзнең яраткан ризыгын, яңа рецепт белән пешерелгән торт, моңарчы беркайчан да ашап карамаган тәм-томанарны пешереп, гаилә белән бер өстәлгә җыелыгыз.





## ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Эклер рецепты

Камыр өчен:
150 гр атланмай яки маргарин, 0,5 чәй калагы тоз, 1,5 стакан он (200 гр), 1,5 стакан су (370 мл), 6 йомырка (эре булса, 5 тә җитә).
Башта камырын әзерлибез.
Савытка су, май, тозны салып кайнатып чыгарабыз.

Кайнап чыккач, газны кысып, газ өстендә генә онны салабыз да әйбәтләп болгатабыз. Сүрән утта 5 минут тирәсе тора. Камыр бераз суынгач, йомырканы берешәрләп салып болгатабыз. Камыр артык куе да, сыек та булырга тиеш түгел. Камырны кондитер капчыгы аша чыгарасың.

Духовкада 15-20 минут 200 градуста, соңыннан 180 градуска кадәр киметеп пешереп бетерәбез.

Кремны ниндине дә ясарга була. Кем ничек ярата. Кибет каймагын, шикәр комы белән болгатып, торт итеп ясарга да була. Минем кремы: 300 гр 33 процентлы сливки, 60 гр шикәр оны, 270 гр эремчекле сыр. Барысын бергә миксер белән болгатабыз. Әзер кремны эклер эченә тутырабыз.






## ӘЙДӘГЕЗ УЙНЫЙБЫЗ!

Без, без, без идек...

Уйнаучылар түгәрәк хасил итеп утыралар. Бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш кулларын бергәләп күтәреп-төшереп болай диләр:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Базга төштек – бал ашадык,
Келәткә кердек – май ашадык,
Өйгә мендек – өйрә эчтек,
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык,
Авызыңны яп та йом!

Шуннан соң уйнаучыларның берсе дә авызын ачмаска, көлмәскә, сөйләшмәскә тиеш. Алар бер-берсен көлдерү өчен төрлечә кыланалар, күз-йөз белән төрлечә ымнар ясыйлар. Кем элек авызын ача йә көлеп җибәрә, аңа «җәза» (шигырь сөйләү, җырлау, бию һ.б.) бирәләр.

Бармак, кайда булдың?

Уен барышы:
Бармакларны күрсәтеп, һәрберсен бөгеп барырга.
Бармак,бармак,
Кайда булдың?
“Бу абый белән
Урманда булдым.
Бу абый белән
Кырда йөгердем.
Бу абый белән
Ботка ашадым.
Бу энем белән
Җыр җырладым”.

## ВАКЫЙГАЛАР ТЕЗМӘСЕ







Ел саен, ноябрьнең соңгы якшәмбесендә, Әниләр көне билгеләп үтелә.Бу бәйрәмнән без дә, Арчаның 7 нче номерлы балалар бакчасында тәрбияләнүче балалар ,читтә калмадык. Чара балалар тарафыннан башкарылган шигырьләр, җыр-биюләр белән үрелеп барды. Бәйрәм ахырында балалар әниләренә үз куллары белән ясалган тәбрикләү открыткалары тапшырдылар. Бәйрәмнән балалар да, әти-әниләр дә бик канәгать калдылар. Алда тагын очрашулар, күңелле мизгелләр күп булсын иде дигән теләктә калабыз.

27 нче ноябрьдә Арчаның 5 нче номерлы балалар бакчасында “Иң яхшы мастер – класс” исеме астында бәйге булып узды. Безнең балалар бакчасыннан Люция Равил кызы чыгыш ясап 1 нче урынга лаек булды. Без аны җиңүе белән котлыйбыз һәм аңа киләчәктә дә шундый актив булуын, яңа үрләргә ирешүен телибез.

29 ноябрь көнне безнең балалар бакчасында инглиз теленә өйрәтү буенча КМО тәрбиячеләренең "Уйнап, инглиз телен өйрәнәбез"дигән темага район утырышы булды. Утырыш инглиз телендә "Алма капчыгы" әкияти тамашасыннан башланды. Эш барышында педагоглар мастер-класслар үткәрделәр, үз эшләнмәләре белән, практик тәҗрибәләр белән уртаклаштылар, уңай эмоцияләр алдылар.

# Мәктәпкә әзерләнәбез

**Беренче сыйныфка баручы бала нәрсә белергә тиеш?**



Улы яки кызы беренче сыйныфка баручы әти-әниләр аеруча зур дулкынлану кичерә. Бигрәк тә аларны беренче сыйныфка баручы баланың нәрсәләр белергә тиешлеге борчый. Түбәндәге киңәшләр нәкъ менә шундый әти-әниләр өчен.

- Исемен, әтисенең исемен һәм фамилиясен.
- Әти-әнисенең һәм якын туганнарының исемнәрен.
- Аларның кайда эшләвен.
- Үзе яшәгән урам исемен, йорт һәм фатир санын.
- Өйдәге, яисә әти-әнисенең кесә телефоннары номерын.
- Нинди илдә һәм шәһәрдә яки авылда яшәвен.
- Ел вакытларын аера, ай исемнәрен әйтергә.
- Атнада ничә көн булуын һәм аларның исемнәрен.
- Яшелчәдән җимешне, йорт хайваннарыннан кыргыйларны аерырга.
- Шигырь, әкиятләр сөйләргә.
- Яхшы әзерлек белән бару өченниләр белергә?
- 0дән 10 кадәр саный һәм саннар рәтендә ялгышмаска.
- Мәсәлән, әгәр 3 санын әйтсәләр, ул шуннан дәвам итәргә тиеш.
- Геометрик фигураларны аерырга.
- Гади генә математик мәсьәләләр чишәргә.
- Охшаш предметларны аерым төркемнәргә бүләргә.

## Мәктәп турында кызыклы фактлар

- Голландиядә яшәүче балалар 4 яшьләре тулган көнне мәктәпкә китәләр. Шуңа күрә сыйныфларда һәрвакыт яңа укучылар була.
- Ашау — Франция мәктәпләрендә белем бирүнең бер өлеше санала. Туклану вакытында укучылар ризыкның ничек ясалуы турында мәгълүмат алалар. Шулай ук, өстәл артында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәнәләр.
- Бангладешта йөздән артык көймә-мәктәп бар. Ел саен су басулар, яңгырлар вакытында юллар ябылу аркасында меңәрләгән бала мәктәпкә йөри алмый. Бу проблеманы суда йөзә торган көймә-мәктәпләр ясап хәл иткәннәр. Мондый уку йортлары кояш батареяларында эшли, интернетка чыгу мөмкинлеге, хәтта китапханәләре бар.
- Татар мәктәпләренең нигез башы булган мәдрәсәләрдә бик күп фәннәр укытылган. Әйтик, Иж-Бубый мәдрәсәсендә фәлсәфә, мантыйк, метафизика, хисап, этика, Россия һәм Шәрык тарихы, гомуми тарих, ислам тарихы, риторика, шигырь төзелеше (гаруз), этика, рус, төрек, фарсы, гарәп, немец һәм француз телләре, рус, татар әдәбияты һ.б. фәннәр укытылган.